ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТУРИЗМУ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТУРИСТЛЫК БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

05.04.2022 Казан ш. № 51

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе утырышын үткәрү өчен нигез булып торган мөрәҗәгатьләрнең, гаризаларның һәм белдерүләрнең алыну тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Президентының 2010 елның 1 июлендәге 821 номерлы указы белән расланган Федераль дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссияләре турындагы нигезләмәнең 16 пунктының «б» пунктчасы, Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 25 августындагы ПУ-569 номерлы указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссияләре турындагы нигезләмәнең 15 пунктының «б» пунктчасы, Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының 2015 елның 9 сентябрендәге 111 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турындагы нигезләмәнең 15 пунктының «б» пунктчасы нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе утырышын үткәрү өчен нигез булып торган мөрәҗәгатьләрнең, гаризаларның һәм белдерүләрнең алыну тәртибен (кушымтада бирелә) расларга.

2. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Рәис С.Е. Иванов

Татарстан Республикасы
Туристлык буенча дәүләт
комитетының 2022 елның
05 апрелендәге 51 номерлы
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе утырышын үткәрү өчен нигез булып торган мөрәҗәгатьләрнең, гаризаларның һәм белдерүләрнең алыну тәртибе

1. Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе утырышын үткәрү өчен нигез булып торган мөрәҗәгатьләрнең, гаризаларның һәм белдерүләрнең алыну тәртибе (алга таба – Тәртип) Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының (алга таба – Дәүләт комитеты) кадрлар һәм юридик эш бүлегенә түбәндәгеләрнең алыну процедурасын билгели:

Дәүләт комитеты боерыгы белән расланган, Дәүләт комитетында вазыйфа биләгәндә дәүләт хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында һәм үзләренең хатынының (иренең) һәм балигълык яшенә җитмәгән балаларының керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга бурычлы булган, вазыйфаны биләү коррупция хәтәрлекләренә бәйле булган Дәүләт комитетының Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлегенә кертелгән Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләгән гражданинның коммерциячел яки коммерциясез оешмада вазыйфа биләүгә хезмәт яисә граждани-хокукый шартнамә шартларында коммерциячел яки коммерциясез оешмада эшләр башкаруга ризалык бирү турында мөрәҗәгате, әгәр әлеге оешманың дәүләт идарәсе буенча аерым функцияләр аның вазыйфаи (хезмәт) бурычларына караган булса, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтеннән куылган көннән соң ике ел узганчыга кадәр;

Дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәреннән (алга таба – дәүләт хезмәткәре) объектив сәбәпләр аркасында хатынының (иренең) һәм балигълык яшенә җитмәгән балаларының керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру мөмкинлеге булмавы турында гариза;

территориясендәге чит ил банкларында счетлары (кертемнәре) булган, нал белән акча чаралары һәм кыйммәтләре саклanган һәм (яисә) чит ил финанс кораллары булган чит ил дәүләтендә компетентлы органнар тарафыннан әлеге чит ил дәүләте законнары нигезендә салынган арестка, эш итүне тыюга бәйле рәвештә яки үз ихтыярына яки хатынының (иренең) һәм балигълык яшенә җитмәгән

балаларының ихтыярына бәйле булмаган башка төрле шартлар аркасында дәүләт хезмәткәреннән – «Аерым категория затларына Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм булдыруны, нал белән акча чаралары һәм кыйммәтләр саклауны, чит ил финанс коралларына ия булуны һәм файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы федераль закон таләпләрен үтәү мөмкинлегенең булмавы турында гариза.

Дәүләт хезмәткәренең вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлыгы барлыкка килүе турындагы белдерүне алу һәм карау тәртибе Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетында Татартан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерергә булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килүе турында хәбәр итү тәртибен раслау турында» 2016 елның 12 февралендәге 18 номерлы боерыгы белән җайга салына.

2. Гражданинның мөрәҗәгатьләре һәм дәүләт хезмәткәренең гаризалары Дәүләт комитеты рәисенә (аның вазыйфаларын башкаручы затка) Дәүләт комитетының кадрлар һәм юридик эш бүлегенең Дәүләт комитетында эшчәнлек алып баруга җаваплы булган белгече аша язмача рәвештә тапшырыла, аларның үрнәге әлеге Тәртипкә 1 нче, 2 нче һәм 3 нче кушымталарда китерелгән.

3. Дәүләт комитеты рәисе (аның вазыйфаларын башкаручы зат) өч эш көне эчендә Дәүләт комитетында коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи затка (алга таба – җаваплы зат) мөрәҗәгатьне (гаризаны) җибәрә.

4. Мөрәҗәгатьне (гаризаны) алдан карау барышында җаваплы зат мөрәҗәгатьне (гаризаны) җибәргән гражданиннан яисә дәүләт хезмәткәреннән анда бәян ителгән хәлләр буенча аңлатмалар соратып ала.

5. Мөрәҗәгатьне (гаризаларны) алдан карау нәтиҗәләре буенча җаваплы зат язмача дәлилләнгән бәяләмә әзерли. Мөрәҗәгать (гариза), граждан яисә дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан мөрәҗәгатькә (гаризага) теркәп тапшырылган материаллар, алдан карау барышында алынган аңлатмалар (булган очракта), шулай ук мөрәҗәгатьне (гаризаны) алган көннән җиде эш көне эчендә алдан карау нәтиҗәләре буенча дәлилләнгән бәяләмә җаваплы зат тарафыннан мөрәҗәгать (гариза) алынганнан соң җиде эш көне эчендә аның тарафыннан Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе (алга таба – Комиссия) рәисенә тапшырыла.

6. Комиссия мөрәҗәгатьне (гаризаны), аңлатмаларны һәм башка материалларны Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының 2015 елның 9 сентябрендәге 111 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан

хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турындагы нигезләмә нигезендә карый.

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенщ карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе утырышын үткәрү өчен нигез булып торган мөрәҗәгатьләрнең, гаризаларның һәм белдерүләрнең алыну тәртибенә 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитеты рәисенә

________________________________________

(юнәлеш килешендә фамилия, инициаллар)

________________________________________

(мөрәҗәгать бирүче гражданинның фамилиясе, исеме, ата исеме (булган очракта),

________________________________________

(иялек килешендә)

Гражданинның яшәү урыны адресы: ____

________________________________________

Гражданинның элемтә телефоны: ______

________________________________________

## Хезмәт шартнамәсе шартларында коммерциячел яки коммерциясез оешмада вазыйфа биләүгә яисә граждани-хокук шартнамәсе шартларында коммерциячел яки коммерциясез оешмада хезмәт күрсәтү яки эш башкаруга ризалык бирү турында мөрәҗәгать

Мин, __________________________________________________________,

(фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта))

Татарстан Республикасы Туризм буенча дәүләт комитетында _______ башлап _______ кадәр дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләдем ________________________________________________________________

________________________________________________________________,

(вазыйфа атамасы)

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законның 12 статьясы нигезендә ризалык бирүегез турында үтенәм:

әлеге вазыйфаны биләп торуга:

________________________________________________________________.

(гражданин биләргә ниятләгән вазыйфаның атамасы)

яки

граждани-хокукый шартнамә шартларында эшләр башкаруга (хезмәт күрсәтүгә)

____________________________________________________________________________.

(гражданин башкарачак эш төрләре, хезмәт күрсәтүнең атамасы)

кайда

___________________________________________________________________________

(коммерциячел оешма яки коммерциясез оешма атамасы)

чөнки әлеге дәүләт граждан хезмәтенең күрсәтелгән вазыйфасын биләгәндә мин әлеге оешмага карата дәүләт идарәсенең* түбәндәге функцияләрен үтәгән идем

____________________________________________________________________________

____________________________________________________________________________.

(ниндиләре икәнен күрсәтергә)

Минем вазыйфама түбәндәгеләр керәчәк (мин башкарачак эш түбәндәгеләрне үз эченә алачак): ____________________________________________________

(вазыйфаи бурычларны кыскача тасвирлау,

____________________________________________________________________________.

граждани-хокукый шартнамә төзегәндә башкарылучы эшнең характеры)

Әлеге мөрәҗәгатьне караганда Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе утырышында шәхсән катнашырга ниятлим/ниятләмим *(кирәклесе астына сызарга)*

Кабул ителгән карар турында мәгълүматны түбәндәге юл белән җибәрүегезне сорыйм:

____________________________________________________________________________

(юллау ысулы күрсәтелә (почта аша, электрон рәвештә, кулга тапшырып һ.б.),

____________________________________________________________________________.

(җибәрү ысулы булып почта аша яки электрон рәвештә җибәрү турында күрсәтелсә,

____________________________________________________________________________.

тиешенчә почта адресы яки электрон почта адресы күрсәтелә)

| | | |
|---|---|---|
| ________________ | ________________ | ______________________________ |
| (дата) | (имза) | (тулы имза) |

* оешманың дәүләт, муниципаль (административ) идарә функцияләрен – дәүләт яки муниципаль хезмәткәр вәкаләтләрен әлеге оешмага карата кадрлар, оештыру-техник, финанс, матди-техник яки башка төрле мәсьәләләр буенча үтәү өчен мәҗбүри карарлар, шул исәптән әлеге оешма тарафыннан эшчәнлекнең билгеле бер төрен гамәлгә ашыруга һәм (яки) аерым гамәлләрне башкаруга рөхсәтләр (лицензияләр) бирүгә бәйле булган карарларны кабул итәргә яисә мондый карарларның проектларын әзерләргә («Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законның 1 статьясы).

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенщ карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе утырышын үткәрү өчен нигез булып торган мөрәҗәгатьләрнең, гаризаларның һәм белдерүләрнең алыну тәртибенә 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитеты рәисенә

______________________________
(юнәлеш килешендә фамилия, инициаллар)

______________________________
(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)

______________________________
(иялек килешендә)

______________________________
(мөрәҗәгать итүченең биләгән вазыйфасы, иялек килешендә)

Объектив сәбәпләр аркасында хатын (ир) һәм балигълык яшенә җитмәгән балаларның керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти холыклы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру мөмкинлеге булмавы турында гариза

Түбәндәгеләргә карата керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәт рәвешендәге холыклы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру мөмкинлегенә ия булмавым турында хәбәр итәм ______________________________________________

______________________________________________________________.
(хатынының, иренең һәм (яки) балигълык яшенә җитмәгән балаларының фамилиясе, исеме,

______________________________________________________________.
атасының исеме (булган очракта), балигъ булмаган балаларның туган көне)

чөнки ______________________________________________________
(Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан

______________________________________________________________
хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе

______________________________________________________________
мәгълүматларны тапшырмау объектив һәм ихтирамга лаек характерда булуы турында нәтиҗә ясый алсын өчен

______________________________________________________________
кирәкле барлык сәбәпләр һәм шартлар күрсәтелә)

______________________________________________________________

Гаризага түбәндәге өстәмә материалларны терким (булган очракта):
_________________________________________________________________________________.
(кушымта итеп бирелә торган материаллар күрсәтелә)

Күрсәтелгән мәгълүматларны тапшыруда дәүләт граждан хезмәткәре күргән чаралар:_______________________________________ .

Әлеге мөрәҗәгатьне караганда Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе утырышында шәхсән катнашырга ниятлим/ниятләмим *(кирәклесе астына сызарга)*

| | | |
|---|---|---|
| _________________ | _______________ | ___________________________________ |
| (дата) | (имза) | (тулы имза) |

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан

хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенщ
карата таләпләр үтәлеше һәм
мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу
комиссиясе утырышын үткәрү өчен нигез
булып торган мөрәҗәгатьләрнең,
гаризаларның һәм белдерүләрнең алыну
тәртибенә 3 нче кушымта

Татарстан Республикасы Туристлык
буенча дәүләт комитеты рәисенә

___________________________________
(юнәлеш килешендә фамилия, инициаллар)

___________________________________
(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме
(булган очракта)

___________________________________
(иялек килешендә)

___________________________________
(мөрәҗәгать итүченең биләгән вазыйфасы, иялек
килешендә)

«Аерым категория затларына Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм булдыруны, нал белән акча чаралары һәм кыйммәтләр саклауны, чит ил финанс коралларына ия булуны һәм файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы федераль закон таләпләрен үтәү мөмкинлегенең булмавы турында гариза

Территориясендәге чит ил банкларында счетлары (кертемнәре) булган, нал белән акча чаралары һәм кыйммәтләре сакланган һәм (яисә) чит ил финанс кораллары булган чит ил дәүләтендә компетентлы органнар тарафыннан әлеге чит ил дәүләте законнары нигезендә салынган арестка, эш итүне тыюга бәйле рәвештә яки үз ихтыярына яки хатынының (иренең) һәм балигълык яшенә җитмәгән балаларының ихтыярына бәйле булмаган башка төрле шартлар аркасында дәүләт хезмәткәреннән «Аерым категория затларына Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм булдыруны, нал белән акча чаралары һәм кыйммәтләр саклауны, чит ил финанс коралларына ия булуны һәм файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы федераль законның (алга таба – Федераль закон) 3 статьясының 1 өлешендәге, 4 статьясының 3 өлешендәге таләпләрен үтәү мөмкинлегенә ия булмавым турында хәбәр итәм, чөнки

______________________________________________________________________
(Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан

___________________________________________________________________________________
хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе
___________________________________________________________________________________
Федераль законның әлеге таләпләрен үтәмәү сәбәбенең объектив һәм ихтирамга лаеклы булуы турында нәтиҗә ясый
___________________________________________________________________________________
алсын өчен кирәкле барлык сәбәпләр һәм шартлар күрсәтелә)
___________________________________________________________________________________.

Гаризага түбәндәге өстәмә материалларны терким (булган очракта):
___________________________________________________________________________________.
(кушымта итеп бирелә торган материаллар күрсәтелә)

Күрсәтелгән мәгълүматларны тапшыруда дәүләт граждан хезмәткәре күргән чаралар:_______________________________________ .

Әлеге мөрәҗәгатьне караганда Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе утырышында шәхсән катнашырга ниятлим/ниятләмим *(кирәклесе астына сызарга)*

| ___________________ | _________________ | _______________________________________ |
|---|---|---|
| (дата) | (имза) | (тулы имза) |